Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Троицкий авыл Советы

КАРАР

30 декабрь 2025 ел № 10

Әлмәт муниципаль районының Яңа Троицкий авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Яңа Троицкий авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә

Яңа Троицкий авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл Советының «Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 79 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл Советының 2018 елның «05» декабрендәге 94 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 10 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 54 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 60 номерлы, 2024 елның 26 июньдәге 100 номерлы,2024 елның 12 декабрендәге 108 номерлы, 2025 елның 20 маендагы 122 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (хезмәткә түләүнең 12 төркеме) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 23 192 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 22 515» |

1.3. карарга 2 нче кушымтада таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (хезмәткә түләүнең 12 төркеме) |
|---|---|
| Башлык | 23 201 |
| Башлык урынбасары | 16 931» |

2. Әлеге карарны Яңа Троицкий авылы, Совет ур., 10 йорт, Шөгерчә авылы, Үзәк урамы, 1 йорты торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Троицкий авыл
җирлеге башлыгы Л.И. Горбунова